ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 08 2022 г. № 557

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 474 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 2 статьясындагы 7 өлеше нигезендә, Кама транспорт прокуратурасының 2022 елның 21 июлендәге 23/1-02-2022 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 474 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләренә кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә (Енькова Я.С.) әлеге карарны матбугат басмасында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (гадәттән тыш хәлләр, гражданнар оборонасы һәм терроризмга каршы эшчәнлек мәсьәләләре буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
җитәкченең беренче урынбасары Р.Ф. Булатов

МКУ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН» «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «23» августа
357 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 474 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләр

1. II «Гомуми таләпләр» бүлегендә:

1.1. 1 пунктның 3 абзацында «һәвәскәрләр» сүзләреннән соң «һәм спорт» сүзен төшереп калдырырга.

1.2. 2 пунктның 5 абзацын төшереп калдырырга.

1.3. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Кече үлчәмле судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Россия Федерациясе су объектларында кече үлчәмле судноларны файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 6 июлендәге 487 номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече үлчәмле судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 15 октябрендәге 562 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.